**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 11 март | № 144

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 февраль, 103 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«бу Тәртипкә теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турындагы актлар күчермәләре.»;

6 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«бу Тәртипкә теркәлгән 5 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турындагы актлар күчермәләре.»;

Тәртипкә теркәлгән 4 нче кушымтаның 1 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле «л» пунктчасын өстәргә:

«л) гадәттән тыш хәл аркасында зыян күргән гражданнар – җирле үзидарә органы яки гадәттән тыш хәл килеп чыккан урын буенча гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе биргән белешмә кәгазен.»;

Тәртипкә бу карарга теркәлгән кушымта редакциясендә бәян ителгән 5 нче кушымта өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\144.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 11 март, 144 нче
карарына кушымта

Форма

## Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында акт

______________________________________________ буенча яшәүче
(адресы)
граждан ______________________________________________,
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме)
адвокат ______________________________________________
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме, адвокат белеменең атамасы)
______________________________________________ тарафыннан
түбәндәге түләүсез юридик ярдәм күрсәтелде:

| Т/с | Түләүсез юридик ярдәмнең төре | Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү датасы | Адвокатларның хезмәте өчен түләү күләме, сум | Күрсәтелгән түләүсез юридик ярдәм бирәмлекләре саны | Адвокатларга хезмәт өчен түләүнең гомуми күләме, сум |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | Телдән хокукый консультация бирү | | | | |
| 2 | Язма рәвештә хокукый консультация бирү | | | | |
| 3 | Дәгъва гаризасын төзү | | | | |
| 4 | Апелляция, кассация, күзәтчелек шикаятен төзү | | | | |
| 5 | Рәсми мөрәҗәгатьләр, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар төзү | | | | |
| 6 | Граждан мәнфәгатьләрен дәүләт органнарында һәм муниципаль орган-нарда, оешмаларда як-лау* | | | | |
| 7 | Судларда граждан мәнфәгатьләрен яклау | | | | |
| 8 | Түләүсез юридик ярдәмне гражданга түбәндәгеләргә барып күрсәтү:** | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | I төркем инвалидның яшәү урыны буенча; психиатрия дәвалау учреждениесенә; өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенә; балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы учреждениесенә, шулай ук балигъ булмаганнарны иректән мәхрүм итү урыннарына | | | | |

* Гражданнарның мәнфәгатьләрен дәүләт органнарында һәм муниципаль органнарда, оешмаларда, судларда яклау, эш озынлыгына карамастан, көн дәвамында адвокат кушкан эшне башкару белән фактта шөгыльләнгән көннәрдә исәпләнә.

** Түләүсез юридик ярдәм күрсәткән өчен адвокатның хезмәт өчен түләү күләме кимендә 50 процентка арттырыла.

Адвокат __________________________/ ____________________________________
(имзасы) (имзасын таркатып язу)

Түләүсез юридик ярдәм
алган граждан __________________________/ _____________________________
(имзасы) (имзасын таркатып язу)

20 ____ ел, _____ ________________